**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Казиле авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**19 ноябрь 2019 ел** **№123**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге "Җир салымы турында»гы 58 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 58 номерлы «Җир салымы турында " карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:»:

2 статьяның 2 пунктында " (индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган)»;

5 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«Сайлап алынган җир участогы турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы икенче абзацы 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Казиле авыл җирлеге Советы Рәисе** **И.Х. Сагьдиев**